КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 апрель г.Казань № 287

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарның пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкән гражданнарның пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 ел, 30 декабрь, 1783 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Декларга теркәлгән Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарның пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче куркыныч төркеменнән эшкә яраклы яшьтән өлкән гражданнарны иммунизацияләү планын расларга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 12 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 15 апрель, 287 нче
карары белән расланды

Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнарның пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану
тәртибе

1. Әлеге Тәртип социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче куркыныч төркеменнән булган хезмәткә сәләтле яшьтән өлкән гражданнарга пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчалардан (алга таба – чаралар) файдалану механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

3. Акчаларны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган шәхси исәп счеты аша гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслануның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә финанслауның чик күләмнәрен җиткерә.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзи (контракт бәясе вакцина, тара, төргәкләү, маркировкалау, саклау, җибәрү, лицензия җыемнары, хезмәт өчен түләү фондын, шулай ук транспорт йөртү, иминиятләү, таможня пошлиналарын түләү, салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләрне үз эченә ала);

дәүләт контрактлары (килешү) шартларына туры китереп, пневмокок инфекциясенә каршы вакциналар сатып алуга дәүләт контрактлары (килешүләре) төзелгән оешмаларга акча күчерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы

Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисаплар тапшыра, финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган бюджетара трансфертларны бирү һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче хезмәткә сәләтле яшьтән өлкән гражданнарның пневмокок инфекциясенә каршы вакцинация уздырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүдә билгеләнгән срокларда һәм, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешү.

7. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

8. Акчаларны максатсыз файдалану Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган акчалар Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

---